СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 28 » сентябрь 2023 ел** **№ 233**

**Арча муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясына, «Россия Федерациясе субъектларында җәмәгать хакимиятен оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законга (алга таба - «Россия Федерациясе субъектларында җәмәгать хакимиятен оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга), «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы 7 статьясына ярашлы рәвештә, Арча район Советы карар бирде:

Арча район Советының 2021 елның 20 апрелендәге 60 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы Уставына (14.10.2022 ел, № 169 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 6 статьяның 1 өлешен түбәндәге эчтәлектәге 45 пункт белән тулыландырырга:

«45) муниципаль район милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләрдә әйләнә-тирә мохиткә зыян китерүче объектларны ачыклау һәм мондый зыянны бетерүне оештыру.»;

2) 31 статьясының 6 пунктының 5 пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алыштырырга;

3) 31 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 13 пункт белән тулыландырырга:

«13. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатының вәкаләтләре әгәр депутат җитди сәбәпләрсез муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы утырышларында алты ай рәттән булмаса, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән вакытыннан алда туктатыла.»;

4) 50 статьяның 2 пунктының 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алыштырырга;

5) 53 статьяның 1 пунктының 3 пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алыштырырга;

6) 53 статьяның 2 пунктындагы 2 пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алыштырырга;

7) 70 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) граждан хезмәткәренең мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм (яки) җайга салу буенча чаралар күрмәве;»;

8) 70 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) граждан хезмәткәренә үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирмәү, алдан ук тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүматлар бирү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш»;

9) 70 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Граждан хезмәткәренең мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләре барлыкка килүе турында белгән яллаучы вәкиле, шулай ук аңа буйсынган граждан хезмәткәренә карата мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм (яки) җайга салу буенча чаралар күрмәгән очракта, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, ышанычны югалту сәбәпле, эштән азат ителергә тиеш.»;

10) 86 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнарның бер тапкыр түләүләр кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда, ә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25_1 статьясының 1 өлешендәге 4, 4_1 һәм 4_3 пунктларында каралган очракларда, гражданнар җыенында хәл ителә.».

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г. Нуриев